**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «О мерах по поддержке республиканского фестивального движения «Созвездие-Йолдызлык»**

В целях усиления поддержки и дальнейшего развития республиканского фестивального движения «Созвездие-Йолдызлык» и в связи с переходом отдельных лиц на другую работу **постановляю**:

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 29 апреля 2006 года № УП-165 «О мерах по поддержке республиканского фестивального движения «Созвездие-Йолдызлык» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 16 июля 2007 года № УП-357, от 17 декабря 2007 года № УП-686, от 17 апреля 2009 года № УП-208, от 20 августа 2012 года № УП-682, от 7 декабря 2012 года № УП-1043, от 17 марта 2015 года № УП-290 и от 16 октября 2015 года № УП-992) следующие изменения:

а) пункт 3 изложить в следующей редакции:

«3. Учредить ежегодные специальные государственные стипендии для победителей открытого республиканского телевизионного молодежного фестиваля эстрадного искусства «Созвездие-Йолдызлык», выплачиваемые единовременно.

Установить, что выплачивается 40 стипендий, в том числе:

семь стипендий – в размере пятнадцати тысяч рублей каждая;

семь стипендий – в размере двадцати тысяч рублей каждая;

семь стипендий – в размере двадцати пяти тысяч рублей каждая;

шесть стипендий – в размере тридцати тысяч рублей каждая;

пять стипендий – в размере тридцати пяти тысяч рублей каждая;

одна стипендия – в размере сорока тысяч рублей;

пять стипендий – в размере пятидесяти тысяч рублей каждая;

Гран-при в номинации «Вокал-соло» – одна стипендия в размере семидесяти тысяч рублей;

Гран-при в номинации «Хореография» – одна стипендия в размере восьмидесяти тысяч рублей.»;

б) в составе Совета при Президенте Республики Татарстан по поддержке республиканского фестивального движения «Созвездие-Йолдызлык» (далее – Совет):

вывести из состава Совета И.Ш. Халикова, Р.Х. Вахитова, А.В. Тыгина;

ввести в состав Совета:

Песошина Алексея Валерьевича – Премьер-министра Республики Татарстан, утвердив его председателем Совета;

Шайхразиева Василя Габтелгаязовича – заместителя Премьер-министра Республики Татарстан, утвердив его заместителем председателя Совета;

изложить в следующей редакции наименования должностей членов Совета при Президенте Республики Татарстан по поддержке республиканского фестивального движения «Созвездие-Йолдызлык»:

И.Ю. Аминова – «генеральный директор акционерного общества «Телерадиокомпания «Новый Век» (по согласованию)»;

М.М. Бариева – «депутат Государственной Думы Федерального Собрания Российской Федерации (по согласованию)».

2. Кабинету Министров Республики Татарстан:

привести свои акты в соответствие с настоящим Указом;

принять иные решения, обеспечивающие реализацию настоящего Указа.

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания. Действие подпункта «а» пункта 1 настоящего Указа распространяется на правоотношения, возникшие с 1 июня 2017 года.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
16 июня 2017 года
№ УП-508

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итү буенча чаралар турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

«Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итүне арттыру һәм аны үстерү максатларында һәм кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итү буенча чаралар турында» 2006 елның 29 апрелендәге ПУ-165 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 16 июлендәге ПУ-357 номерлы, 2007 елның 17 декабрендәге ПУ-686 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-208 номерлы, 2012 елның 20 августындагы ПУ-682 номерлы, 2012 елның 7 декабрендәге ПУ-1043 номерлы, 2015 елның 17 мартындагы ПУ-290 номерлы һәм 2015 елның 16 октябрендәге ПУ-992 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. «Созвездие-Йолдызлык» республика ачык телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивалендә җиңүчеләргә бер тапкыр түләнә торган еллык махсус дәүләт стипендияләрен гамәлгә куярга.

40 стипендия түләнә дип билгеләргә, шул исәптән:

җиде стипендия – һәрберсе унбиш мең сум күләмендә;

җиде стипендия – һәрберсе егерме мең сум күләмендә;

җиде стипендия – һәрберсе егерме биш мең сум күләмендә;

алты стипендия – һәрберсе утыз мең сум күләмендә;

биш стипендия – һәрберсе утыз биш мең сум күләмендә;

бер стипендия – кырык мең сум күләмендә;

биш стипендия – һәрберсе илле мең сум күләмендә;

«Вокал-соло» номинациясендә Гран-при – бер стипендия җитмеш мең сум күләмендә;

«Хореография» номинациясендә Гран-при – бер стипендия сиксән мең сум күләмендә.»;

б) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы «Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итү буенча совет (алга таба – Совет) составында:

Совет составыннан И.Ш. Халиковны, Р.Х. Вахитовны, А.В. Тыгинны чыгарырга;

Совет составына кертергә:

Песошин Алексей Валерьевичны – Татарстан Республикасы Премьер-министрын, аны Совет рәисе итеп расларга;

Шәйхразиев Васил Габделгаяз улын – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарын, аны Совет рәисе урынбасары итеп расларга;

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы «Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итү буенча совет әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

И.Ю. Әминовның – «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)»;

М.М. Бариевның – «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты (килешү буенча)».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

үз актларын әлеге Указга туры китерергә;

әлеге Указны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә. Әлеге Указның 1 пункты «а» пунктчасының гамәле 2017 елның 1 июненнән соң барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2017 ел, 16 июнь
№ ПУ-508